ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ГОРОДА ИННОПОЛИС

ул. Спортивная, д.114, г.Иннополис, Верхнеуслонский район, Республика Татарстан, 420500

ИННОПОЛИС ШӘҺӘРЕНЕҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Спортивная ур., 114-нче йорт, Иннополис шәһәре, Югары Ослан районы, Татарстан Республикасы, 420500

тел. (843) 212-27-24, e-mail: city@innopolis.ru, www.verhniy-uslon.tatarstan.ru/rus/innopolis.htm

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

23.01.2018 | г. Иннополис | № 3

2018 елда Иннополис шәһәре территориясендә авыл хуҗалыгы продукциясен һәм көндәлек кирәк-яракларын сату ярминкәләрен оештыру турында

«Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләти җайга салу нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә ярминкәләр оештыру һәм аларда товарлар сату (эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү) тәртибен раслау турында» 2011 елның 4 мартындагы 171 номерлы карары нигезендә, Иннополис шәһәре Башкарма комитеты,

КАРАР БИРӘ:

1. Иннополис шәһәре территориясендә «Татарстан Республикасы территориясендә ярминкәләр оештыру һәм аларда товарлар сату (эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү) тәртибен раслау турында " Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 4 мартындагы 171 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә авыл хуҗалыгы продукциясен һәм көндәлек азык - төлек товарларын (алга таба-ярминкәләр) сату буенча атна саен ярминкәләр  (алга таба-ярминкәләр) оештырырга.

2. Ярминкәләрне оештыручы буларак «Иннополис шәһәре үсеше фонды» автономияле коммерциячел булмаган оешманы билгеләргә (ОГРН 11516000970, ИНН 1615012041, теркәү адресы: Татарстан Республикасы, Югары Ослан районы, Иннополис шәһәре, Спорт ур., 114, пом.1).

3. Ярминкәне оештыручыга түбәндәге адрес буенча ярминкәләрдә катнашуга гаризалар кабул итүне тәэмин итәргә: Татарстан Республикасы, Югары Ослан районы, Иннополис ш., Спорт ур., 114 й.,   1 п., эш вакытында: 9:00дән 18:00гә кадәр (ярминкәне оештыручы ягыннан вәкаләтле зат - «Иннополис шәһәре үсеш фонды» коммерциячел күчемсез мөлкәтне арендалау менеджеры).

4. Ярминкәләрне уздыру графигын һәм срокларын расларга - атна саен (чәршәмбе яисә җомга), 2018 елның 24 гыйнварыннан 2018 елның 26 декабренә кадәр.

5. Ярминкәләр үткәрү урынын һәм сәүдә урыннарын урнаштыру схемасын, 1 нче кушымта нигезендә расларга. Сәүдә урыннары саны: 6 урын.

6. Ярминкәнең тибын һәм төрен: махсуслаштырылган, тематик төрен билгеләргә.

7.Ярминкәләр әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты составын 2 нче кушымта нигезендә расларга.

8. Иннополис шәһәре территориясендә ярминкәдә сәүдә урыннары бирү тәртибен, 3 нче кушымта нигезендә расларга. Ярминкәдә катнашучыларга күрсәтелгән Тәртип нигезендә сәүдә урыннары бирүне тәэмин итәргә.

9. «Иннополис шәһәр хуҗалыгын эксплуатацияләү хезмәте» МБУ ярминкәләр үткәрү урынын җыештыруны һәм тиешле хәлдә тотуны тәэмин итәргә.

10. Россия Эчке эшләр министрлыгының “Югары Ослан” муниципальара бүлеге начальнигына полиция полковнигы О.Е. Хохоринга җәяүлеләр һәм автомобиль транспорты хәрәкәтенең җәмәгать тәртибен һәм куркынычсызлыгын, ярминкәләрдә катнашучыларның автомобиль транспорты ярминкәләрен үткәрү урынына каршылыксыз баруын тәэмин итәргә.

11. Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Яшел Үзән, Югары Ослан, Кама Тамагы районнарында территориаль бүлеге башлыгы Е.К. Агеевага ярминкәләр үткәрү урынында юридик һәм физик затлар тарафыннан санитар нормаларның һәм кагыйдәләрнең үтәлешен контрольдә тотуны оештырырга тәкъдим итәргә. -

12. «Югары Ослан район дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесе башлыгы М.Ф. Зиатдиновка Ярминкә үткәрелгән урыннарда ветеринария таләпләренең юридик һәм физик затларның үтәлешен тикшереп торуны оештырырга.

13. «Федераль янгынга каршы хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча 8 отряды» ФДКУның янгын сүндерү-коткару бүлеге башлыгы А.А. Әхмәтҗановка янгынга каршы нормаларны үтәүне контрольдә тотарга.

14. 7 көн эчендә әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Интернет челтәрендә Югары Ослан муниципаль районының мәгълүмати сайтына (http://verhniy-uslon.tatarstan.ru/) урнаштырырга .

15. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р.Р. Шагалеев

Иннополис шәһәре Башкарма
комитетының ________
№____________ карарына
1 нче кушымта

2018 елда Иннополис шәһәре территориясендә көндәлек кирәк-ярак товарларын һәм авыл хуҗалыгы продукциясен сату ярминкәләрен уздыру урыны

Үткәрү урыны: Татарстан Республикасы, Югары Ослан районы, Иннополис шәһәре, урман-парк территориясе, Спорт урамындагы 106 нчы йорт янында.

ЯРМИНКӘДӘ СӘҮДӘ УРЫННАРЫН УРНАШТЫРУ СХЕМАСЫ



Иннополис шәһәре Башкарма комитетының ________ №____________ карарына
2 нче кушымта

2018 елда Иннополис шәһәре территориясендә авыл хуҗалыгы продукциясен һәм көндәлек азык-төлек товарларын сату ярминкәләрен әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты составы

| | |
|---|---|
| Р. Р. Шагалиев | Оештыру комитеты рәисе, Иннополис шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе |
| И.Р. Хуззәтов | Оештыру комитеты рәисе урынбасары, Иннополис шәһәре Башкарма комитетының социаль һәм торак сәясәте бүлеге башлыгы |
| А. А. Емельянов | Оештыручы, «Иннополис шәһәре үсеш фонды» АНО директоры |
| А. А. Шиһапов | «Иннополис шәһәрен үстерү фонды» АНО оештыручы вәкаләтле хезмәткәре, коммерциячел күчемсез милекне арендалау менеджеры |
| Д.А. Арефьев | Россия Эчке эшләр министрлыгының «Югары Ослан» муниципальара бүлеге полиция начальнигы урынбасары полиция подполковнигы<br>(килешү буенча) |
| Р.К. Садыйкова | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Зеленодольск, Югары Ослан, Кама Тамагы районнарында территориаль бүлеге башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| М.Ф. Зиатдинов | «Югары Ослан район дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесе башлыгы (килешү буенча) |

Иннополис шәһәре Башкарма комитетының ________
№____________ карарына
3 нче кушымта

Иннополис шәһәре территориясендә ярминкәдә сәүдә урыннары бирү тәртибе

Әлеге Тәртип Иннополис шәһәре территориясендә ярминкәләрдә катнашучыларга (алга таба текст буенча - ярминкәләр) сату (эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү) өчен сәүдә урыннары бирүгә төп таләпләрне билгели.

Ярминкәдә катнашучыларга товарларны сату (эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү) өчен сәүдә урыннары бирү заявка нигезендә гамәлгә ашырыла.

Ярминкәләрдә катнашуга заявка, әлеге Тәртипкә кушымта нигезендә, билгеләнгән форма нигезендә, вәкаләтле оештыручы хезмәткәренә язма рәвештә бирелә.

Ярминкәләрне оештыручы, ярминкәләрдә катнашучыларга карата таләпләрне (сайлап алу критерийларын) исәпкә алып, ярминкәләрдә катнашу өчен гаризалар сайлап алу хокукына ия.

Ярминкәләрдә катнашучыларга карата таләпләр (сайлап алу критерийлары).

- сатыла торган продукциягә товар озату документлары булу;

- Крестьян (фермер) яисә шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарның, яисә бакчачылык, терлекчелек белән шөгыльләнүче гражданнарның - крестьян (фермер) яисә шәхси ярдәмче хуҗалык алып баруны раслый торган документы булу яисә бакчачылык, яшелчәчелек, терлекчелек белән шөгыльләнү (эшчәнлекне гамәлгә ашыру урыны буенча җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелә торган хуҗалык кенәгәсеннән белешмә яки өземтә);

- кануннар таләпләре нигезендә продукциянең сыйфатын, килеп чыгышын һәм иминлеген раслый торган документлар булу;

- сатыла торган продукциянең бөтен ассортиментына бәяләр булу;

- продукция җитештерүче исемен һәм аны теркәү урынын күрсәтеп, мәгълүмати табличка булу;

- Югары Ослан муниципаль районында Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсеннән белешмә булу, ул тиешле муниципаль районда эшчәнлек алып бару фактын раслый йә ярминкәдә катнашучы территориясендә эшчәнлек алып барган Россия Федерациясенең башка субъекты вәкаләтле органының шундый ук белешмәсе.

Документлар сатучыларда ярминкә эше дәвамында саклана һәм вәкаләтле дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары вазыйфаи затлары таләбе буенча күрсәтелә.

Катнашучыны теркәү.

Ярминкәдә катнашуга заявка ярминкәне оештыручы вәкаләтле зат тарафыннан теркәлә.

Гаризаны теркәгән көннән алып 3 эш көне эчендә әлеге Тәртип таләпләренә туры килү-килмәүгә заявка карала, шуннан соң мөрәҗәгать итүчене ярминкәләрдә катнашучылар составына кертү яисә ярминкәләрдә катнашучылар составына кертүдән баш тарту турында карар кабул ителә.

Ярминкәләрдә үз продукциясен сату мөмкинлеген бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

- сәүдә мәйданчыкларында буш сәүдә урыннары булмау;

- гаризада әлеге Тәртип таләпләре нигезендә мәгълүматны тулысынча күрсәтмәү;

- әлеге Тәртиптә санап үтелгән таләпләргә туры килмәү.

Мөрәҗәгать итүчене ярминкәләрдә катнашучылар исемлегенә кертү турында яки ярминкәләрдә катнашучылар исемлегенә кертүдән баш тарту турында карар кабул ителгәннән соң, оештыручы биш эш көне эчендә мөрәҗәгать итүчегә кабул ителгән карар турында хәбәр итә (телефон элемтәсе һәм/яисә электрон почта аша).

Иннополис шәһәре территориясендә ярминкәдә сәүдә урыннары бирү тәртибенә
Кушымта

Ярминкәне оештыручы: ______________________________
Адрес: ______________________________

Иннополис шәһәре территориясендәге ярминкәләрдә катнашуга
ГАРИЗА

Оешманың исеме: ______________________________________________
(ҖЧҖ, ИП, КФХ, ШЯХ, йә башкасы)
Катнашучы Ф.И.А: ______________________________________________
_______________________________________________________________
Фактик адрес: ________________________________________________
_______________________________________________________________
Контакт телефоны: _____________________________________________
E-mail:
_______________________________________________________________
Ярминкәдә катнашу даталары: _________________________________
_______________________________________________________________
Ярминкәдә тәкъдим ителгән товарлар (эшләр, хезмәтләр) атамасы: __________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________

Кушымта:

1. Фермер хуҗалыгын (КФХны) яисә шәхси ярдәмче хуҗалыкны (ШЯХ) яисә башка гамәлгә кую документын алып баруны раслый торган Устав (ООО), таныклык (ИП);
2. Продукциянең сыйфатын һәм куркынычсызлыгын раслый торган документлар (форма буенча);
3. Билгеләнгән үрнәктәге медицина китабы (персонал өчен).

Әлеге документны имзалаганда, мин шуны раслыйм: Иннополис шәһәре территориясендә ярминкәләр оештыру һәм аларга товар сату тәртибенең шартлары белән, шулай ук Иннополис шәһәре территориясендә ярминкәләрдә катнашучыларны сайлап алу тәртибенең шартлары белән танышкан (-а) һәм (-на) килешәм, һәм үз өстемә күрсәтелгән документларда каралган җаваплылык тотарга йөкләмә алам.

________________________ ____________________ ______________________________
*Исеме (Ф.И.О.)* *Имза* *Киңәйтеп язу, мөһер*

"____" ____________ 2018 ел